КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 май г.Казань № 494

Татарстан республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу турында

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә «Вознесение тракты. Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, $VII^1$ бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә «Вознесение тракты. Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Вознесение торак массивы, Бахтизин урамы, 26 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Г.М.Кесель (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) милкендә булган, торак пунктлар җирләре категориясендәге 500 кв.метр мәйданлы, 16:50:270101:1503 кадастр номерлы җир кишәрлеген, аның территориясендә урнашкан 108,4 кв.метр мәйданлы, 16:50:270101:1996 кадастр номерлы капиталь төзелеш объектын һәм күчемсез

мөлкәт объектларын (алга таба – алына торган мөлкәт) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган мөлкәт өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен мөлкәтне алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган мөлкәт милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган мөлкәт өчен түләү;

алына торган мөлкәткә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәве;

алына торган мөлкәт милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин